КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 март г.Казань № 224

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 21 сентябрь, 808 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2018 ел, 21 сентябрь, 808 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар һәм күләмнәрнең 3 пунктында «641,48», «718,78» һәм «2 150,37» саннарын шул ук эзлеклелектә «672,65», «753,71» һәм «2 209,54» саннарына алыштырырга;

Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр әзерләү буенча эш башкаруга норматив чыгымнарның 3 пунктында «7 733 385,5», «1 461 514,2» һәм «167 250,7» саннарын шул ук эзлеклелектә «8 089 162,1», «1 522 578,6» һәм «168 534,3» саннарына алыштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин